# КАРАР

29 ноябрь, 2024 ел                                                                                    № 2

Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Янил авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 29 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Янил авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Янил авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү);

2. урам яктыртуны ясау (Янил авылында урам яктыртуны карап тоту, ясау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

3. су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (Янил авылының Үзәк урамында су белән тәэмин итү системалары төзү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

4. торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Янил авылындагы юлларга вак таш җәю һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Янил авылында урам юл челтәрен карап тоту; юл билгеләре сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

5. тротуарлар ясау, ремонтлау (җәяүлеләр кичүен һәм тротуарны ремонтлау, төзү һәм карап тоту; тротуар өчен бордюрлар сатып алу, урнаштыру һәм алар тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

6. торак пункт территориясен төзекләндерү ( йорт төзү, урнаштыру, ремонтлау; Янил авылында күпләп ял итү урыннарын һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

7. традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Янил авылы зиратлары территориясен, янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү һәм карап тоту, зиратларның коймаларын ремонтлау һәм карап тоту, җирләү йортларын ремонтлау, зиратка илтә торган җәяүлеләр күперен ремонтлау, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру) ?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 452 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 238 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 235 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 3 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Янил авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 650 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Янил авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү);

2. урам яктыртуны ясау (Янил авылында урам яктыртуны карап тоту, ясау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

3. су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (Янил авылының Үзәк урамында су белән тәэмин итү системалары төзү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

4. торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Янил авылындагы юлларга вак таш, асфальт-бетон түшәмә җәю һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Янил авылында урам юл челтәрен карап тоту; юл билгеләре сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

5. тротуарлар ясау, ремонтлау (җәяүлеләр кичүен һәм тротуарны ремонтлау, төзү һәм карап тоту; тротуар өчен бордюрлар сатып алу, урнаштыру һәм алар тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

6. торак пункт территориясен төзекләндерү (Янил авылында күпләп ял итү урыннарын һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

7. традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Янил авылы зиратлары территориясен, янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү һәм карап тоту, зиратларның коймаларын ремонтлау һәм карап тоту, җирләү йортларын ремонтлау, зиратка илтә торган җәяүлеләр күперен ремонтлау, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру) ?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х. Корбанов